СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**30 октябрь 2023 ел** **№ 4**

**Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш – Аты авылында Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 22 ноябренә 18 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 22 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Кооператив, Яңа урамнарда яшәүчеләр

2нче этап: Тарлау, 9 Май урамнарда яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш-Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан

тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәрендә янмый торган лампочкаларны алыштыру өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;
- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу;
- грейдер хезмәтләре өчен түләү ?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"»

5. Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Утар - Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар - Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ